**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**III чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**III созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
от 28.04.2020г

**РЕШЕНИЕ**
№46-03

Яңа коронавирус инфекциясе таралуга бәйле хәлләрнең начараюы шартларында Актаныш муниципаль районы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча чаралар планын тормышка ашыру турында

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р.Сираеваның яңа коронавирус инфекциясе таралуга бәйле хәлләрнең начараюы шартларында Актаныш муниципаль районы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча чаралар планын тормышка ашыру турындагы докладын тыңлаганнан соң, Актаныш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р.Сираеваның Актаныш муниципаль районы икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча яңа коронавирус йогышы таралуга бәйле хәлләрнең начараюы шартларында чаралар планын тормышка ашыру турында мәгълүматны игътибарга алырга (кушымта итеп бирелә).

2. Барлык предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләренә, Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнарына үз эшчәнлекләрендә әлеге карарга таянып эш итәргә, куелган бурычларны тормышка ашыруда һәм әлеге карарның үтәлешен тәэмин итүдә актив катнашырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе И.И.Габделхаевка йөкләргә.

Актаныш муниципаль район
Советы рәисе

Э.Н.Фәттахов